АКТАНЫШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423740,село Актаныш, Проспект Ленина,дом 58.Тел.3-44-40

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423740, Актаныш авылы, Ленин проспекты, 58 нче йорт. Тел.3-44-40

**КАРАР**

№ 4 «18» гыйнвар 2021 ел

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлегендә балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиянең 2021 елга эш планын раслау турында**

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 14.10.2011 № 71-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Актаныш авыл җирлеге Уставы нигезендә, балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау, гаиләләр белән профилактик эш алып бару максатыннан Актаныш авыл башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. Актаныш авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре буенча иҗтимагый комиссиянең 2021 елга эш планын (1 нче кушымта) расларга.

**2.**Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында Актаныш авыл җирлеге бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Актаныш авыл Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Р.Шарипов

Актаныш авыл җирлеге
башкарма комитеты
18.01.2021 ел № 4 карарына
кушымта

Актаныш авыл җирлегендә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең 2021 елга эш планы

| № п/п | Чара | Үткәрү вакыты | Җаваплылар | чара кем белән берлектә үткәреләчәк |
|---|---|---|---|---|

Оештыру-методик эш

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышы (Татарстан Республикасы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Актаныш районындагы беркетмәләре һәм күрсәтмәләре буенча балигъ булмаган балаларга һәм аларның ата-аналарына карата материалларны карау, белем бирү учреждениеләре тәкъдимнәре һәм үтенечнамәләре, гражданнарның шикаятьләре, торак шартларын тикшерү актлары һ. б.) | Кварталга 1 тапкыр | Комиссия рәисе, сәркатибе | комиссия составы |
| 2. | Авыл җирлеге территориясендә балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенең күчмә утырышларын үткәрү | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | комиссия составы |
| 3. | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия рейдлары | Ел дәвамында | комиссия рәисе | комиссия составы, мәгариф, мәдәният учреждениеләре |
| 4. | Балигъ булмаганнар арасында эчкечелекне кисәтү максатыннан яшүсмерләр концентрациясе урыннары | Ел дәвамында | Комиссия рәисе | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | (дискотекалар, урамнар) буенча рейдлар | | | |
| 5. | Сәүдә нокталары буенча рейдлар | Ел дәвамында | комиссия рәисе | комиссия составы |
| 6. | Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы КДН һәм ЗП утырышларында чыгарылган штрафлардан качып йөрүче гражданнар буенча рейдлар | Ел дәвамында | комиссия рәисе | комиссия составы |
| 7. | Имин булмаган гаиләләрне ачыклау һәм аларны КДН, ЗП һәм ПДНда исәпкә кую | Ел дәвамында | комиссия рәисе | комиссия составы |
| 8. | Балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча яшүсмерләр һәм аларның ата-аналарын кабул итү | Ел дәвамында | комиссия рәисе | комиссия составы |
| 9. | Гаилә көненә, Балаларны яклау көненә, Яңа елга багышланган чаралар оештыру һәм үткәрү | Ел дәвамында | комиссия рәисе | комиссия составы, җирлекнең мәдәният учреждениеләре |

Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия утырышында карау өчен чыгарылган мәсьәләләр

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге территориясендә балигъ булмаганнар арасында хокук бозулар һәм җинаятьләрнең торышы турында | Квартал саен | комиссия рәисе | комиссия составы |
| 2 | Дәресләргә кермәгән балалар турында мәгълүмат һәм мондый очракларга юл куймау буенча җирлек мәгариф учреждениеләре тарафыннан күрелгән чаралар һәм мәктәпкә кайтару буенча балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклаучы комиссия составы турында | Ел дәвамында | комиссия рәисе | комиссия составы, белем бирү учрежденияләре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Яшәү урыны буенча балигъ булмаганнарның ялын оештыру турында | Ел дәвамында | комиссия рәисе | комиссия составы, белем бирү учреждениеләре |
| 4 | Күп балалы һәм имин булмаган гаиләләр белән эшләү | Ел дәвамында | комиссия рәисе | комиссия составы |
| 5 | Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча Комиссия эшенә йомгак ясау | Ел ахырында | комиссия рәисе | комиссия составы |